| | |
|---|---|
| СОВЕТ САЛИХОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>САЛИХ АВЫЛ<br>ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

17.06.2024 с.Новые Чути № 111

Салих авыл җирлеге Советының 25.05.2023 ел, №77 «Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» карарына (15.02.2024 ел, №98 үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә.

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясының 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Салих авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Салих авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Салих авыл җирлеге Советының 25.05.2023 ел, №77 «Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» карарына (15.02.2024 ел, №98 үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2. 1 нче пунктны түбәндәге пункт белән тулыландырырга: "8) физик затларда җирле салымнар буенча бурычлар булу Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән сроклар тәмамланганнан соң 500 сумнан артмаган сумма.»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга pravo.tatarstan.ru һәм Баулы муниципаль районы сайтында bavly.tatarstan.ru.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккач үз көченә керә һәм 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә үз көчен җәелдерә.

Сәлих авыл җирлеге башлыгы З. С. Галләметдинов